ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 май, 2020 ел № 39/13

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советына депутатлар сайлауларын уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын төгәлләштерү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә, шәһәр территориясе үсеше, яңа микрорайон барлыкка килү һәм яңа йортлар файдалануга тапшырылу белән бәйле рәвештә бермандатлы сайлау округларының гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатларында

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/23 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бермандатлы сайлау округларын тасвирлауны, 17 номерлы «Тулпар» сайлау округына «53,» сүзләреннән соң «63,» сүзләрен өстәп, төгәлләштерергә.

2. Әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев